ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
УТАР-АТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Кооперативная, д. 22, с. Утар-Аты,
Арский муниципальный район, 422017

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УТАР-АТЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Кооператив урамы, 22 йорт, Утар-Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422017

Тел. (84366)50-3-31, факс (84366)50-4-22. E-mail: Utat.Ars@tatar.ru

# КАРАР

« 30 » гыйнвар 2023 ел № 1

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Утар-Аты авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру тәртибен раслау һәм салым чыгымнарын бәяләү турында» Татарстан Республикасы Утар-Аты авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 28 апрелендәге 9 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе субъектлары һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 июнендәге 1081 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлеге башкарма комитетының 28.04.2021 ел, № 9 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 3 пунктта «муниципаль программаларның структур элементларын» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) икенче абзацтагы 12 пунктта «муниципаль программаларның структур элементларына» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan/ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Утар-Аты авыл
җирлеге башлыгы А.Г.Мөхәмәтгалиева